РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраля 2018 г. №14

21 февраль, 2018 ел, №14

**Түбән Кама шәһәр Советының “Татарстан Республикасы “Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында” 2016 елның 21 мартындагы 3нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**
(Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 4нче карары редакциясендә)

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы № 25-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының « Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013елның 25 июнендәге № 50-ЗРТ Законы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының “Татарстан Республикасы “Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында” 2016 елның 21 мартындагы 3нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (1нче кушымта).

2. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт үтү турындагы норматив-хокукый актларын гамәлдәге Нигезләмәгә туры китерергә.

3. Карар үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советы регламент, җирле үзидарә һәм депутатлык этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

**Кушымта**
Түбән Кама шәһәр Советының
2018 елның 21февралендәге
14нче карарына

Түбән Кама шәһәр Советының “Татарстан Республикасы “Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында”гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 6нчы маддәне түбәндәге эчтәлектәге 6.4 пункты белән тулыландырырга:
«6.4. Белгеч яки югары нәтиҗәле магистр дипломына ия затлар өчен диплом бирелгән көннән өч ел дәвамында белгечлеге буенча вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре муниципаль хезмәт стажына яки эш стажына, әйдәп баручы муниципаль хезмәт вазыйфалары - кимендә ярты ел стаж муниципаль хезмәт яки белгечлеге буенча бер ел эш стажына бәйле».
2. 14нче маддәдә:
1) 14.3 пунктта « һәм Федераль закон белән» сүзләренә «2012 елның 3 декабреннән № 230-ФЗ» сүзләрен өстәргә;
2) түбәндәге эчтәлектәге 14.7 пункты белән тулыландырырга:
«14.7. Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар һәм күрсәтелгән вазыйфаны алыштыручы зат үзләренең һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының табышлары, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматны, Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим итәләр»;
3) түбәндәге эчтәлектәге 14.8 пункты белән тулыландырырга:
«14.8. Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы зат үзенең табышлары, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматны Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмати- телекоммуникацион челтәрендә урнаштыра»;
4) түбәндәге эчтәлектәге 14.9 пункты белән тулыландырырга:
«14.9. Гамәлдәге маддәнең 14.7 пунктындагы контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар һәм күрсәтелгән вазыйфаны алыштыручы зат үзләренең һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының табышлары, чыгымнары, мөлкәте турындагы мәгълүматның дөреслеге һәм тулылыгы Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә, Татарстан Республикасы законы таләп иткән тәртиптә тикшерелә»;
5) түбәндәге эчтәлектәге 14.10 пункты белән тулыландырырга:
«14.10. Гамәлдәге маддәнең 14.9 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы № 25-ФЗ Федераль законы, “Дәүләт хезмәткәре вазыйфаларын башкаручы затларның чыгымнары туры килү контроле турында” 2012елның 3 декабрендәге № 230-ФЗ Федераль законы нигезендә, “Аерым категория затларга Россия Федерациясе

территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тотуны, акчалата чаралар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (я) алардан файдалануны тыю турындагы" 07.05.2013 № 79-ФЗ федераль законы нигезендә, Татарстан Президенты контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасындагы затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында яки әлеге затка карата дисциплинар җәза кылу хокукына ия җирле үзидарә органына, яки судка мөрәҗәгать итә».

3. 20нче маддәдә:

1) 20.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.3. Муниципаль хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле отпуск 30 календарь көн тәшкил итә»;

2) 20.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.4. Муниципаль хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпусклар тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда һәм әлеге Законда каралган очракларда бирелә. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпускның озынлыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән чыгып санала. Ел саен бирелә торган түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпускның гомуми озынлыгы 40 календарь көннән артмаска тиеш. Нормалаштырылмаган эш көне өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпуск, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпусклар ел саен бирелә торган түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпускның әлеге өлештә каралган гомуми көннәргә өстәп бирелә."

Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина